ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАТАРСКО-САРСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422976, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
д.Татарский Сарсаз, улица Центральная, дом 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР САРСАЗЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422976, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Татар Сарсазы авылы,
Центральная урамы, 4 нче йорт

e-mail: Tsarz.Ctp@tatar.ru, тел. (84342) 4-64-05

Постановление Карар

№3 26 гыйнвар 2024 ел

Татар Сарсазы авыл җирлеге Башкарма комитетының
2023 елның 26 гыйнварындагы
2 номерлы карарының 1 пункты үз көчен югалтуын тану турында

«Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2023 елның 25 октябрендәге 26/1 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге Башкарма комитетының вәкаләтләрен (вәкаләтләренең бер өлешен) тапшыру турындагы 20.11.2023 елгы килешү нигезендә, Чистай муниципаль районының Татар Сарсазы авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Сарсазы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»гы Татар Сарсазы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 26 гыйнварындагы 2 номерлы карарының 1 пункты үз көчен югалтуын танырга.
2. Әлеге карар 2024 елның 01 февралендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татар Сарсазы авыл җирлеге
башлыгы С.С.Мусин